**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# КАРАРЫ

*2020 елның 23сентябре* *379 №*

«2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында мәдәният һәм сәнгатьне үстерү, районның тарихи-мәдәни мирасын саклау, музейларны комплекслы үстерү, китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерү, районның милли мәдәният традицияләрен саклау, үзешчән сәнгать коллективларының һәм башкаручыларның, рәсем сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының иҗади мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук балаларга һәм яшьләргә эстетик әхлакый тәрбия бирү, яшь талантларга ярдәм итү максатыннан Башкарма комитет КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасын (алга таба – Программа) расларга (Кушымта).

2. Авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, шулай ук Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә муниципаль Программа чараларының үтәлешен тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУнә чираттагы елга бюджет формалаштырганда Программа чараларын тормышка ашыру өчен финанс чараларын күздә тотарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**җитәкчесе**
**Башкарма комитет** **И. В. Юсупов**

Башкаручы: А. М. Әхмәтҗанова
тел.8(84346)21015

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 23 сентябре 379 № карарына кушымта

## «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль Программасы

### Программа паспорты

| | |
|---|---|
| **Программа исеме** | «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| **Программаны эшләүче** | «Әлки район мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе |
| **Программаның максатлары** | Татарстан Республикасы халкының мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендәге агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру.<br>Район халкы һәм Татарстан Республикасы кунаклары өчен мәдәният учреждениеләренең җәлеп итүчәнлеген арттыру. |
| **Программаның бурычлары** | Мәдәният һәм сәнгатьне үстерү өчен шартлар тудыру, районның тарихи-мәдәни мирасын саклау.<br>Музейларны комплекслы үстерү.<br>Гражданнарга аларның мәгълүматтан һәм белемнәрдән ирекле файдалануга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү юлы белән китапханә хезмәте күрсәтү системасын үстерү, шулай ук китапханәләрдә сакланган милли мәдәни мирасны саклау, район халкының китапханә өлкәсенә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңаларын булдыру, китапханә учреждениеләренең имиджын күтәрү.<br>Районның милли мәдәният традицияләрен үстерүне саклап калу.<br>Районның үзешчән сәнгать коллективлары һәм башкаручылары, сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.<br>Кино челтәренең тотрыклы үсешенә ирешү.<br>Балаларга һәм яшьләргә эстетик әхлакый тәрбия бирү өчен шартлар тудыру, районның яшь талантларына ярдәм итү.<br>Мәдәният учреждениеләренең матди-техник |

| | |
|---|---|
| | базасын ныгыту.<br>Мәдәният учреждениеләрен югары квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү.<br>Мәдәният хезмәткәрләренең социаль-икътисади проблемаларын хәл итү. |
| **Программаны тормышка ашыру вакыты** | 2021-2024 еллар |
| **Бүлекләр исемлеге** | 1. Һөнәри сәнгатькә һәм һөнәри иҗатка адреслы ярдәм күрсәтү.<br>2. Мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау һәм яклау.<br>3. 2021-2024 елларга музейлар һәм музей фонды үсеше.<br>4. Сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү, сәнгать һәм һөнәри белем бирү системасын алга таба үстерү<br>5.Китапханә эшен модернизацияләү һәм китапханә фондын үстерү.<br>6. Милли мәдәниятне саклау һәм үстерү.<br>7. Кинематографияне, прокатка алу һәм кинофильмнар күрсәтүне үстерү.<br>8. Мәдәният өлкәсендә бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген арттыру, мәдәният өлкәсенә өстәмә ресурслар җәлеп итү өчен шартлар тудыру.<br>9. Милләтара мәдәни хезмәттәшлекне алга таба үстерү һәм милли - мәдәни җәмгыятьләр һәм автономияләр белән мөнәсәбәтләрне җайга салу.<br>10.Кадрлар әзерләү һәм мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә социаль ярдәм күрсәтү. |
| **Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | Программаны финанслау республика бюджеты һәм Әлки муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар хисабына башкарылачак.<br>2021-2024 елларга Программаны тормышка ашыру өчен финанслау күләме 6295,0 мең сум күләмендә планлаштырыла, шул исәптән еллар буенча:<br>**2021 ел – 1585,0 мең сум;**<br>**2022 ел – 1575,0 мең сум;**<br>**2023 ел-1610,0 мең сум;**<br>**2024 ел – 1525,0 мең сум.**<br>Искәрмә: программаны финанслау күләме |

| | |
|---|---|
| | фаразланган характерда һәм тиешле финанс елына һәм план чорына «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | Районның социаль-мәдәни үзгәртеп коруларында мәдәният, сәнгать учреждениеләренең ролен күтәрү.<br>Район халкының интеллектуаль әхлакый һәм иҗади потенциалын арттыру.<br>Районның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү, шулай ук һөнәри үзешчән халык иҗатын үстерү.<br>Иҗади коллективларның санын 10% ка һәм аларда катнашучыларны 20% ка, чараларны 20% ка, тамашачыларны 30% ка, киносеансларга йөрү 10% ка, алардан тулай җыемны 10% ка арттырырга.<br>Музейларга йөрешне 50% ка кадәр, музей фонды 35% ка арттыру.<br>Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының бердәм мәгълүмат системасын үстерү һәм һәркем өчен мөмкин булган китапханәләр эшчәнлеген модернизацияләү:<br>-үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләре сайтларының санын 100% ка кадәр арттыру.<br>үзәкләштерелгән китапханә системасындагы бердәм электрон каталогны үзәкләштерү һәм һәр авыл китапханәсе белән тулыландыру.<br>- БУБ (бердәм укучы билеты) буенча хезмәт күрсәтелә торган укучылар санын 100% ка кадәр арттыру.<br>- үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләре эш практикасына электрон документацияне кертү .<br>- үзәкләштерелгән китапханәләр системасы фондын туплау күләмен 50% ка, китап укучыны китап белән тәэмин ителешне 25% ка, бер кешене - 20% ка кадәр арттыру.<br>Балалар музыка мәктәбе укучыларының контингентын 15% ка арттыру.<br>Мәдәният өлкәсендә кадрлар потенциалын 15% ка үстерү. |
| **Программаны башкаручылар** | «Әлки район мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;<br>«Әлки район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>«Әлки җирлекара үзәк китапханәсе» муниципаль |

| | |
|---|---|
| | бюджет мәдәният учреждениесе;<br>«С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее»муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе<br>П. П. Хузангай исемендәге музей;<br>«Әлки киноучреждениесе» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>«Әлки балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;<br>«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе;<br>Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге. |
| **Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү** | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күздә тотыла:<br>- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы халкының мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсен күтәрү;<br>- Мәдәни-ял чараларында катнашучылар санын арттыру<br>- Музей учреждениеләренә йөрешне һәм музей фондын арттыру<br>- Халыкка китапханә хезмәте күрсәтү, китапханәләргә йөрү һәм китап бирү санын арттыру;<br>- Мәдәни мирас объектларын теркәү һәм паспортлаштыру<br>- Кино күрсәтүне арттыру<br>- Белем бирү процессының сыйфатын күтәрү<br>- Түләүле хезмәтләрне арттыру |
| **Программа үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы** | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны тормышка ашыруны координацияләү һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра |

**Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән хәл итүне нигезләү**

Әлки муниципаль районы милли мәдәниятне, телне үстерү, район территориясендә яшәүче гражданнарның үзенчәлеген саклап калу өчен шартлар тәэмин итәрлек бай мәдәни потенциалга ия.

Районда эшчәнлек алып бара - район мәдәният йорты, 29 авыл мәдәният йорты, 18 авыл клубы учреждениесе, шулай ук автоклуб һәм агиткультбригада

…әни агитация төркеме), гомуми фонды 349194 данә китаплы 36 китапханә, … филиалы булган туган як музее: «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган …кны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе, П.П.Хузангай музее, 125 кешелек укучылар контингенты булган балалар музыка мәктәбе, «Колос» кинотеатры, 1 тарих, мәдәният һәм архитектура һәйкәле, 2 гыйбадәтханә корылмасы, традицион кабер ташлы 2 зират, 3 археологик объект. 2 - Федераль әһәмияттәге, 93 республика әһәмиятендәге, 23 - җирле әһәмияттәге.

Район китапханәләре тарафыннан 15386 укучыга хезмәт күрсәтелә, бу китапханә хезмәте күрсәтүнең 81% ын тәшкил итә. Китап белән тәэмин ителеш китап укучыга - 22, яшәүчегә - 18 нөсхә. Музей учреждениеләре 8000гә якын кешегә хезмәт күрсәтә, кино күрсәтү 739 сеанс тәшкил итә, аларны 3754 тамашачыны караган. Районда 104 иҗат коллективы эшли, аларда 1505 катнашучы шөгыльләнә, җиде коллектив «Халык»исеменә лаек булды. Халыкка мәдәни хезмәт күрсәтү белән 179 кеше шөгыльләнә. Белгечләр белән тәэмин ителеш: клублар - 60,9%, китапханәләр - 66%, музейлар - 50% , педагоглар - 75%. Клуб учреждениеләрендә кадрлар агымы (алмашынуы) 3,6 % тәшкил итә. Белгечләрнең уртача айлык хезмәт хакы 27950 сум тәшкил итә.

Әмма мәдәният учреждениеләренең матди базасы түбән һәм халыкның мәдәни ихтыяҗлары һәм аларны канәгатьләндерү мөмкинлекләре арасында аерманы зур. 6 мәдәният учреждениесе капиталь ремонтка мохтаҗ. Күпчелек биналарның физик тузуы 60% тан артык, ә җиһазларның тузуы 70% ка кадәр җитә. Клуб учреждениеләре көчәйтү аппаратурасы белән 48%ка, җиһазлар һәм техник чаралар белән 24%ка, сәхнә костюмнары белән 30%ка тәэмин ителгән, бу уздырыла торган чаралар һәм күрсәтелә торган мәдәни хезмәтләр сыйфатына йогынты ясый.

Планлаштырылган капиталь ремонт һәм яңа цифрлы 3D-җиһазлар урнаштыру белән бәйле рәвештә, кинотеатрда яңа сыйфатлы фильмнар күрсәтү мөмкинлеге артты, кинотеатрга килүчеләр саны, узган ел белән чагыштырганда, артты. Әмма кинозалны яңа заманча креслолар белән тәэмин итү һәм килүчеләр өчен гардероб оештыру буенча техник мәсьәләләр хәл ителмәгән булып кала бирә.

Мәдәният учреждениеләренең түләүле хезмәтләреннән кергән керемне дә күбәйтергә кирәк.

Китапханәләр эшендә иң актуаль проблемаларның берсе-китапханә фондын сыйфатлы яңартуны тәэмин итү. Тармак һәм балалар әдәбиятына ихтыяҗ зур. Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы фондының яңартылышы нибары 1,5% тәшкил итә (норматив-5%). Күп еллар дәвамында вакытлы матбугатка язылу өчен финанслау күләме үзгәрмәде. Әмма бәянең ел саен артуына бәйле рәвештә, бу сумма девальвацияләнә һәм нәтиҗәдә, ел саен газета һәм журналларны яздыру азая бара.

Безнең республикада үсеп килүче буынга эстетик тәрбия бирү мәсьәләләре аеруча зур әһәмияткә ия. Музыка мәктәбе укучыларының уңышын укытучылар һәм анда эшләүче башка хезмәткәрләр тәэмин итә. Шуңа күрә Оешма персоналына аерым игътибар бирелә. Хәзерге вакытта Әлки балалар музыка мәктәбе кадрларга, яшь белгечләргә кытлык кичерә. Коллективта 60 яшьтән узган пенсионерлар 50% тәшкил итә.

Персонал белән идарә итү системасының төп максаты - оешма үсеше. Оешмада персонал белән идарә итүнең бурычы булып укытучылар составында кирәкле һөнәр һәм квалификация булдыру; оешма структурасында кадрларның сан һәм сыйфат составының оптималь нисбәте; хезмәткәрнең һәм коллективның тулаем потенциалыннан нәтиҗәле файдалану; хезмәт дисциплинасын күтәрү һәм карьера үсешен үстерү өчен кадрларны дөрес үстерү; квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү; җитәкчелек карарларының үтәлешен тикшерү тора.

Килеп туган вәзгыятькә анализ күрсәткәнчә, бу проблемаларны хәл итү дәүләт, иҗтимагый, иҗади, коммерциячел оешмалар, учреждениеләр һәм хезмәтләр көчләрен берләштереп кенә мөмкин. Ә мондый вәзгыять бурычларны программа методлары белән хәл итүне күздә тота.

2021-2024 елларга Әлки муниципаль районында мәдәниятне үстерү программасы дәүләт тарафыннан районда мәдәниятне үстерүгә гарантияле ярдәм күрсәтүне; халыкның мәдәни тормышта катнашуы һәм үсеше өчен шартлар тудыруны; һөнәри үзешчән сәнгать иҗатын үстерүне; сәнгать өлкәсендә өстәмә белем бирүнең сыйфатын күтәрүне, сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмасының яшь белгечләре тарафыннан һөнәри әзерлек алды әзерлеген үстерү һәм гамәлгә ашыруны; тарихи-мәдәни мирасны саклауны; киноучреждениеләрнең тотрыклы үсешен, кинофильмнарны прокатлау һәм күрсәтүне; мәдәни байлыклардан файдалану мөмкинлеген; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районын дөнья киңлегенә кертүне; бюджет акчаларын мәдәният үсешенең өстенлекле юнәлешенә туплауны тәэмин итәргә тиеш.

1. «2021-2024 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘДӘНИ... ҮСТЕРҮ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

**1. Һөнәри сәнгатькә һәм һөнәри иҗатка ярдәм итү**

| т/б № | исеме Чара | Җаваплы башкаручы | Үтәү вакыты (ел) | Финанслау чыганаклары | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1. | "Алтын битлек" балалар театр коллективлары конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 2 | "Русская песня" хәзерге заман һәм халык рус җырларын башкаручылар конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 3 | "Каравон" рус фольклоры фестивале | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 4 | Халык иҗаты бәйрәме "Уйнагыз, гармуннар!" | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 5 | "Татарстан -безнең уртак йортыбыз" милли мәдәният бәйрәме | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 6 | Татар җырын үзешчән башкаручылар конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Өлкән яшьтәге үзешчән башкаручылар республикакүләм «Балкыш-Сияние» фестивале | Башкарма комитет, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | [illegible] |
| 8 | КВН бәйгесе (татар телендә) | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 4 | 4 | 4 | 4 | 16 |
| 9 | Мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри осталык конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 10 | "Шома бас" татар халык биюен башкару буенча хореография коллективлары смотры | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 11 | Театр коллективларының «Идел-йорт» төбәкара фестиваль-конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 12 | «Иделкәем» балалар театр коллективларының республика фестиваль-конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 13 | "Һәр торак пунктка үрнәк мәдәният учреждениесе" республика конкурсы | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 14 | «Әйлән-бәйлән» төбәкара татар милли бию фестивале | ТР ММ, МБ | 2021-2024 еллар. | Җирле бюджет | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 15 | Авыл җирлегендә социаль-мәдәни проектларны гамәлгә ашыру буенча ирекле (волонтер) эшләрне үстерү һәм аларга ярдәм итү | Башкарма комитет, МБ | 2021-2024 еллар | Җирле бюджет | 1 | 1 | 1 | 1 | 4 |
| | **Барлыгы** | | | | **70,0** | **70,0** | **70,0** | **70,0** | **280,0** |

## 2. Мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы һәм яклавы

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты (ел) | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1 | Әлки муниципаль районының күчемсез мәдәни-тарихи мирасын саклау һәм куллану. Һәйкәлләрне ачыклау, өйрәнү, паспортлаштыру, консервацияләү һәм агымдагы ремонтлау. ТР Әлки МР «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее»муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе "Туган якны өйрәнү музее" муниципаль бюджет учреждениесе бинасы яңадан ачыкланган мәдәни мирас объекты дип санала. Капиталь ремонт таләп ителә. | Мәдәният бүлеге, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 2 | Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклап калу буенча сак чаралары (күрсәткечләр, коймалар, агымдагы ремонт һ.б.) үткәрү. | Мәдәният бүлеге, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары | 2021-2024 еллар. | 30 | 10 | 30 | 10 | 80 |
| 3 | Җимерелә торган һәйкәлләрдә консервация һәм аварияга каршы башка эшләр башкару | Мәдәният бүлеге, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары | 2021-2024 еллар. | 10 | 30 | 10 | 30 | 80 |
| | **Барлыгы:** | | | **50,0** | **50,0** | **50,0** | **50,0** | **200,0** |

**3. 2021-2024 елларда музейлар һәм музей фонды үсеше**

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты (еллар) | Еллар буенча чыгымнар суммасы-мең сум. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1. | Музей фондын төбәк тарихы буенча предметлар белән тәэмин итү | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 20 | 20 | 30 | 30 | 100 |
| 2. | Музейның янгын куркынычсызлыгы | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 15 | 10 | 15 | 10 | 50 |
| 3. | Музей коллекцияләрен реставрацияләү | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 0 | 15 | 15 | 20 | 50 |
| 4. | Музей фондының сакланышын тәэмин итү (сакчылык-янгын сигнализациясе системасы, видеокүзәтү белән тәэмин итү) | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 30 Лисенков музеенда видео күзәтү | 20 П. П. Хузангай музеенда видеокүзәтү | 30 Лисенков музееда янгын сигнализациясе системасын алыштыру | 20 П. П. Хузангай музеенда янгын сигнализациясе системасын җиһазлау | 100 |
| 5. | Нәшрият эшчәнлеге | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 10 | 20 | 5 | 10 | 45 |
| 6. | Мәдәни-белем бирү чараларын үткәрү | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны | 2021 - 2024 | 20 | 5 | 10 | 10 | 45 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өйрәнү музее» МБМУ | | | | | | |
| 7. | Туган якны өйрәнү буенча фәнни-тикшеренү эше | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 5 | 10 | 20 | 5 | 40 |
| 8. | Туган як музее экспозициясен камилләштерү һәм яңарту | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 10 | 20 | 5 | 10 | 45 |
| 9. | Квалификацияне арттыру, яңадан һөнәри әзерлек һәм республика музей берләшмәсе тормышында катнашу. | «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021 - 2024 | 20 | 10 | 10 | 5 | 45 |
| | **Барлыгы:** | | | **130,0** | **130,0** | **140,0** | **120,0** | **520,0** |

## 4. Сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү, сәнгать һәм һөнәри белем бирү системасын алга таба үстерү

| т/б №№ | Чаралар исеме | Җаваплылар | Үтәү вакыты | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум.) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1. | Музыка кораллары сатып алу | Балалар музыка мәктәбе | 2021-2024 | 0 | 20 | 20 | 20 | 60 |
| 2. | Нота һәм укыту әдәбияты сатып алу | Балалар музыка мәктәбе | 2021-2024 | 20 | 10 | 10 | 10 | 50 |
| 3. | Хореография һәм театр сәнгате бүлекләре укучылары, хор һәм халык уен кораллары ансамбле өчен сәхнә костюмнары тегү | Балалар музыка мәктәбе | 2021-2024 | 100 | 100 | 100 | 100 | 400 |
| 4. | Сәләтле балаларга район ярдәме һәм социаль яклау чараларын гамәлгә ашыру:<br>Төрле региональ, республика, бөтенроссия, | Балалар музыка мәктәбе | 2021-2024 | 60 | 60 | 60 | 60 | 240 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | халыкара дәрәҗәсендәге балалар иҗаты фестивальләре, конкурслары, күргәзмәләре, спектакльләре үткәрү. | | | | | | | |
| 5. | Укытучыларның педагогик осталыгын күтәрү. Укытучыларның семинарларда, педагогик осталык конкурсларында, төрле региональ, республика, бөтенроссия, халыкара дәрәҗәсендәге методик эшләрдә, шул исәптән Казан, Әлмәт, Яр Чаллы шәһәрләрендә мастер-классларда катнашуы. | Балалар музыка мәктәбе | 2021-2024 | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| | **Барлыгы:** | | | **200,0** | **210,0** | **210,0** | **210,0** | **830,0** |

## 5. Китапханә эшен модернизацияләү һәм китапханә фондларын үстерү.

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәлеш вакыты (ел) | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум.) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел. | 2022 ел. | 2023 ел. | 2024 ел. | Барлыгы |
| 1 | комплектлаштыруны һәм комплектлаштырып бетерүне (җирле бюджет) тәэмин итәргә | Мәдәният бүлеге, «ҮКС» МБУ | 2021-2024 | 100 | 100 | 100 | 100 | 400 |
| 2 | "Руслан" системасында электрон каталоглар булдыру, китапханәләрөчен техника сатып алу (электрон уку билетлары, штрих-кодлар, санаучылар) | ТР ММ, ТР Милли китапханәсе, Мәдәният бүлеге, «ҮКС» МБУ | 2021-2024 | 10 | 5 | 10 | 5 | 30 |
| 3 | Китап фондларының иминлеген тәэмин итү шартларын гамәлдәге нормативларга туры китерү: керү ишекләрен ныгыту, тәрәзәләргә рәшәткәләр урнаштыру.<br>Һәр китапханә учреждениесенә янгын инвентаре сатып алу | Мәдәният бүлеге, АҖБК «ҮКС» МБУ | 2021-2024 | 25 | 20 | 20 | 25 | 90 |
| 4 | Кулланучыларга хезмәт күрсәтүне оештыру; халыкка мәгълүмати-китапханә хезмәте күрсәтүнең заманча оештыру формасы буларак Әлки ҮКСын саклап калу;<br>«2014-2022 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын (2019 | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | елнын 6 июнендәге үзгәрешләр белән), «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» ТР Законын; РФдә балалар һәм яшүсмерләр укуына ярдәм итү Концепциясен (Программасы) (РФ Хөкүмәтенең 1155 номерлы Күрсәтмәсе); Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Укучының мәдәни нормативы» мәдәни-белем бирү проектын; 2018-2024 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга «Әлки җирлекара үзәк китапханәсе» МБУнең үсеш стратегиясен; «Балачак Уныеллыгы» федераль социаль программасын; «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә дәүләт гаилә сәясәте концепциясе»н һ. б.тормышка ашыру | | | 5 | 5 | 5 | 5 | |
| 6 | Китапханә җиһазлары белән тәэмин итү: уку һәм компьютер өстәлләре, стеллажлар, урындыклар, китап шкафлары, кафедралар, жалюзилар | ТР ММ, РБК, мәдәният бүлеге, «ҮКС» МБУ | 2021-2024 | 15 | 15 | 15 | 15 | 60 |
| 7 | Китапханә эше өлкәсендә норматив, методик һәм лингвистик аспектларны үстерү;<br>Китапханә эшен регламентлаштыручы хокукый норматив актлар эшләү;<br>Китапханә эше практикасына нәтиҗәле форма һәм методлар кертү, китапханәчеләрнең иҗади инициативасын үстерү;<br>ҮКС һәм А/Ф эшчәнлеген регламентлаштыручы документларны эшләү һәм раслау;<br>«Ел китабы» республика конкурсында катнашу;<br>ТР ММ премиясенә «Лидер» республика конкурсында катнашу;<br>ТР ММ премиясенә «Иҗади эзләнү» республика конкурсында катнашу;<br>Ел саен үткәрелә торган «Ел балалар китапханәсе» конкурсының «Авыл һәм балалар» номинациясендә катнашу;<br>«Елның балалар китапханәчесе» республика | «ҮКС» МБУ<br>ТР ММ, ТР МК<br>ТР ММ, ТР МК<br>ТР ММ, ТР МК<br>ТР РБК, ҮБК | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | конкурсында катнашу;<br>Авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан иң яхшы мәдәният учреждениеләрен һәм аларның хезмәткәрләрен акчалата бүләкләүгә республика конкурсында катнашу<br>ТР ММ грантына Иҗади проектлар республика конкурсында катнашу<br>Ел саен Бөтенроссия китапханәләр көнен үткәрү | ТР РБК, ҮБК<br><br>ТР ММ,<br><br>ТР ММ ҮК, жирле бюджет<br><br>Мәдәният бүлеге, «ҮКС» МБУ | | | | | | |
| 8 | Балалар, яшьләр һәм башка халык төркемнәренең мәгълүмати танып-белү һәм эстетик ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча ҮКС эшен оештыру. Китап һәм укуны үстерү буенча мәдәни-агарту эшчәнлеген киңәйтү. ҮКС практикасына инновацион нәтиҗәле эш формалары һәм методларын кертү (мәнфәгатьләр клублары, китап театрлары, флеш-моблар, җәйге уку заллары, электрон презентацияләр һ. б.);<br>ҮКС эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча мәдәни-белем бирү һәм танып-белү-күңел ачу чараларын үткәрү;<br>Милли мәдәният китапханә-үзәкләре эшен ныгыту һәм камилләштерү (рус мәдәнияте үзәге - Юхмачы АК; чуаш мәдәнияте үзәге - Хузангай АК; татар мәдәнияте үзәге -Түбән Әлки АК);<br>Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга китапханә хезмәте күрсәтү үзәге буларак ҮБКен ныгыту;<br>Район китапханәләре тарихын торгызу эшен дәвам итәргә;<br>Мөмкинлекләре чикләнгән балаларга хезмәт күрсәтү;<br>Инвалидларга өйдә хезмәт күрсәтү;<br>Шәхси иҗади проектларны тормышка ашыру;<br>«Укучының мәдәни нормативы» республика | Мәдәният бүлеге, «ҮКС» МБУ, | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | проектын тормышка ашыру;<br>Китапханә-филиалларның максатчан программаларын тормышка ашыру | | | | | | | |
| | **Барлыгы:** | | | **175,0** | **165,0** | **170,0** | **170,0** | **680,0** |

| Белгечләр белән тәэмин ителеш | 2021 ел |
|---|---|
| Китапханә | 66% |
| Клуб учреждениеләре | 60,9% |
| Балалар музыка мәктәбе | 100% |

**Китапханәләргә вакытлы матбугат керү.**

| Китапханә исеме | газета | | журналлар | |
|---|---|---|---|---|
| | норма | факт | норма | факт |
| Авыл | 20 | 4 | 20 | 5 |
| ҮБ | 50 | 23 | 70 | 34 |
| БК | 40 | 6 | 60 | 23 |

**Китапханәләргә китаплар килү.**

| Китапханә исеме | норма | факт | % |
|---|---|---|---|
| Авыл | 500 | 262 | 52% |
| ҮБ | 5000 | 794 | 16% |
| БК | 6000 | 363 | 6% |

**6.Милли мәдәниятне саклау һәм үстерү**

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты (еллар) | Чыгымнар суммасы еллар буенча (м.с.) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1. | ТР Әлки муниципаль районы Советы каршында милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне үстерү буенча даими комиссия төзү. | Мәдәният бүлегенең берләштерелгән советы | 2021-2024 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Район мәдәният йорты методик кабинеты тарафыннан методик ярдәмче әдәбият нәшер итү. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | |
| 3. | Клуб учреждениеләре каршындагы Милли-мәдәни үзәкләрне үстерү: Демидовка АК (рус), Әхмәт АМЙ (татар), Хузангай АК (чуаш), Иске Карата АМЙ (чуаш), Югары Әлморза АМЙ (татар), Иске Матак АМЙ (чуаш), Югары Әлки АК (татар), Югары Кәчи АК (чуаш), СадиковоАК (рус) | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, МБУ, АҖБК | 2021-2024 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4. | Халык - сәнгать һәм декоратив кәсепләре буенча күргәзмәләр-ярминкәләр, фестивальләр уздыру, шулай ук республика дәрәҗәсендәге шундый чараларда катнашу. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, МБУ, АҖБК | 2021-2024 | 50 | 50 | 50 | 50 | 200 |
| 5. | Массакүләм мәгълүмат чараларында, соц. челтәрләрдә милли мәдәниятне саклау һәм үстерү чараларын даими яктырту. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6. | Район Сабантуе һәм авыл Сабантуе | РБК, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, мәдәният бүлеге, АҖБК | 2021-2024 | 50 | 50 | 50 | 50 | 200 |
| 7. | Республика Көне. Авыл көне. «Әлки ягы гасырларда яшә»милли мәдәният бәйрәме. Халык бәйрәме. | РБК бүлеге, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 50 | 50 | 50 | 50 | 200 |
| 8. | Милли Нәүрүз бәйрәме. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| 9. | Район бәйрәме Май чабу, Кышны озату. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| 10. | Питрау бәйрәме. | АҖБК мәдәният бүлеге | 2021-2024 | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| 11. | Милли бәйрәм «Рамазан» | «РМЙ» МБУ, АҖБК | 2021-2024 | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| 12. | Милли «Корбан гаете»бәйрәме | «РМЙ» МБУ, АҖБК | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 13 | «Троица» рус бәйрәме (фольклор бәйрәме). | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | АҖБК | | | | | | |
| 14. | Раштуа җырлары. Раштуа очрашулары, утырулар. | Мәдәният бүлеге, АҖБК | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 15. | Пасха күңел ачулары, уеннар, балалар өчен әйлән-бәйлән уйнаулар. | Мәдәният бүлеге, АҖБК | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 16. | "Каз өмәсе" милли бәйрәме. | Мәдәният бүлеге, АҖБК | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 17. | Алмагач спасы. Бәлеш бәйрәме.<br>Бал спасы. Балалар өчен баллы тәм-томнар бәйрәме. | Мәдәният бүлеге, АҖБК | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 18. | «Уяв»чуаш милли бәйрәме. | АҖБК мәдәният бүлеге | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 19. | Яңа ел  яшьләр Бал-Маскарадлары. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, АМЙ,  авыл җирлеге | 2021-2024 | 50 | 50 | 50 | 50 | 200 |
| 20. | Балалар өчен Яңа ел тамашалары. | Мәдәният бүлеге, РМЙ,АМЙ, АҖБК | 2021-2024 | 50 | 50 | 50 | 50 | 200 |
| 21. | Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне. Гаилә бәйрәмнәре. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, АМЙ | 2021-2024 | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| 22. | Әниләр Көне. (бәйрәм концертлары, күп балалы әниләрне, солдат әниләрен, тыл хезмәтчәннәрен хөрмәтләү) | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, АМЙ | 2021-2024 | 30 | 30 | 30 | 30 | 120 |
| 23. | Ватанны Саклаучылар көне. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, АМЙ | 2021-2024 | 30 | 30 | 30 | 30 | 120 |
| 24. | Талантлы яшьләрнең район фестивале. | РБК, ЯССБ, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 25. | Халыкара өлкәннәр көне.(концертлар, ветераннарны һәм тыл хезмәтчәннәрен хөрмәтләү) | «РМЙ» МБУ, СЯБ, АМЙ | 2021-2024 | 30 | 30 | 30 | 30 | 120 |
| 26. | Халыкара хатын-кызлар көне. Бәйрәм чаралары. | «РМЙ» МБУ, АМЙ | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 27. | Мәдәният хезмәткәрләре көне. Һөнәри бәйрәм. | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28. | Яшьләр көзге балы. Детские Осинины. | «РМЙ» МБУ, АМЙ | 2021-2024 | 15 | 15 | 15 | 15 | [illegible] |
| 29. | Җиңү Көне. Тематик чаралар циклы. | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, АМЙ | 2021-2024 | 30 | 30 | 30 | 30 | 120 |
| 30. | Район китап укучылар һәм үзешчән авторлар конкурсы. | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 31. | Тантаналы рәвештә паспортлар тапшыру | Мәдәният бүлеге, РБК,<br>Әлки районында ТР буенча РФ ФМХИ ТП | 2021-2024 | 1 | 1 | 1 | 1 | 4 |
| 32. | Һөнәри бәйрәмнәр үткәрү | Мәдәният бүлеге, РМЙ, РБК | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 33. | Район хәрби хезмәткә чакырылучылар көне | Хәрби комиссариат, ЯССБ, мәдәният бүлеге | 2021-2024 | 1 | 1 | 1 | 1 | 4 |
| 34. | Авыл җирлекләре, учреждение һәм оешмалар арасында район үзешчән халык иҗаты смотр-конкурсы | «РМЙ» МБУ, АМЙ, мәдәният бүлеге, оешма җитәкчеләре | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 35. | Клуб формированиеләрен булдыру һәм гамәлдәгеләренә ярдәм итү. | Мәдәният бүлеге | 2021-2024 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 36. | «Иң яхшы директор», «Иң яхшы сәнгать җитәкчесе», «Иң яхшы клуб мөдире» район конкурсын үткәрү. | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 37. | Яңа сәнгать коллективлары төзү, балалар иҗатын оештыру. Фольклор коллективларын булдыру. | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 38. | «Наркотикларсыз тормыш», «Без сәламәт яшәү рәвеше өчен», «Экстремизмга юк», «Яшь экологлар», «Туган якны өйрәнүче яшьләр», «Без Ватаныбызны яратабыз» акцияләрен үткәрү. | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 39. | Үзешчән сәнгать осталарын «халык» исемен | «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | биргүгә әзерләү. | мәдәният бүлеге, | | | | | | |
| 40. | «РФ Дәүләт флагы көне» - чаралар циклы | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 6 | 6 | 6 | 6 | 24 |
| 41. | Халыклар бердәмлеге көне - чаралар циклы | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 42. | Россия бәйсезлеге көне-чаралар циклы | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 43. | Россия Геройлары көне-чаралар циклы | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 44. | Балаларны яклау көне-театральләштерелгән тамаша | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 15 | 15 | 15 | 15 | 60 |
| 45. | Белем көне-театральләштерелгән тамаша | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 46. | «Чуаш утары» проекты белән республика Сабантуен уздыруда катнашу | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 47. | «Яңа уңыш әйлән-бәйләне» фольклор бәйрәме | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, АМЙ, АК | 2021-2024 | 12 | 12 | 12 | 12 | 48 |
| 48. | «Түгәрәк уен» татар фольклоры район фестиваль-конкурсы | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 49. | "Исәнме, газиз авыл" - кече авыл бәйрәмнәре. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| | **Барлыгы:** | | | **720,0** | **720,0** | **720,0** | **720,0** | **2880,0** |

## 7. КИНЕМАТОГРАФИЯНЕ, ПРОКАТКА АЛУ ҺӘМ КИНОФИЛЬМНАР КҮРСӘТҮНЕ ҮСТЕРҮ

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты (еллар) | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум.) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1 | Ел саен үткәрелә торган массакүләм чаралар һәм кинофестивальләр:<br>«Балалар киносының зур бәйрәме»<br>«Казан халыкара мөселман киносы фестивале»<br>"Киномарафон-Җиңү яктысы»<br>Тормыш иминлеге нигезләре, төрле белем тармакларын пропагандалау буенча социаль юнәлешле чаралар.<br>«Хокук бозуларны профилактикалау һәм хокукый аң формалаштыру»<br>Тематик кино күрсәтү:<br>«Ватаным»<br>«Экран һәм китап»<br>«Хатын-кыз, Җир бизәге!»<br>«Татарстан. Гасырлар һәм еллар»,<br>«Өлкәннәр көне»,<br>«Наркотикларсыз дөнья өчен»<br>«Сәламәт яшәү рәвеше - сәламәт милләт»<br>«Сак булыгыз ут»<br>«Бөек Җиңү»<br>«Язмышыңны җимермә», репертуар план нигезендә әһәмиятле даталарга багышланган башка кино чаралары.<br>Ел саен Россия киносы көнен үткәрү | Киноучреждение | 2021-2024 еллар. | 50 | 50 | 50 | 50 | 200 |
| 2 | «Колос» кинотеатры бинасында сак сигнализациясе урнаштыру | | 2021-2024 еллар. | 50 | 50 | 50 | 0 | 150 |
| | **Барлыгы:** | | | **100,0** | **100,0** | **100,0** | **50,0** | **350,0** |

**8.Милләтара мәдәни хезмәттәшлекне алга таба үстерү һәм милли-мәдәни җәмгыятьләр һәм автономияләр белән мөнәсәбәтләрне жа[...] салу.**

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты (еллар) | Чыгымнар суммасы еллар буенча (м.с.) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1 | Сәнгать коллективларының һәм аерым башкаручыларның Республика, Халыкара һәм Россия конкурсларында катнашуы:<br>- "Уяв" - республика. Чуаш мәдәнияте бәйрәме - «Каравон», Бөтенроссия рус фольклоры фестивале, Казан шәһәре «Сабантуй»да «Чуаш утары» проекты | Мәдәният бүлеге, МБ, ЯССБ | 2021-2024 еллар. | 30 | 30 | 30 | 30 | 120 |
| 2 | Ел саен «Сабантуй» регионара бәйрәмендә сәнгать коллективларының һәм аерым башкаручыларның катнашуы | РМЙ, РБК, мәдәният бүлеге | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3 | Төбәкара килешүне үтәү нигезендә сәнгать коллективлары һәм аерым башкаручыларның Пенза шәһәрендә, Ульяновск өлк., Чуваш Республикасында чыгышлары | РМЙ, РБК, мәдәният бүлеге | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4 | «Безнең йорт - Татарстан» республика этномәдәни фестивалендә катнашу | Мәдәният бүлеге, МБ | 2021-2024 еллар. | 10 | 5 | 10 | 5 | 30 |
| 5 | Татар халык биюе<br>һәм «Шома бас» этнографик биюе буенча хореография һәм фольклор коллективларының республика смотр-конкурсында катнашу | Мәдәният бүлеге, МБ | 2021-2024 еллар. | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 6 | «Балкыш» («Сияние») ветераннар арасында үзешчән башкаручыларның республика фестивале | РБК, мәдәният бүлеге | 2021-2024 еллар. | 20 | 10 | 20 | 10 | 60 |
| 7 | Әлки районында Татарстан Республикасы, БДБ илләре һәм чит ил делегацияләре очрашуы | РБК, мәдәният бүлеге, ЯССБ, МБ | 2021-2024 еллар. | 5 | 5 | 5 | 5 | 20 |
| 8 | Хатын-кыз, ана һәм гаилә матурлыгы республика конкурсы «Нечкәбил»дә катнашу | РБК, мәдәният бүлеге | 2021-2024 еллар. | 15 | 15 | 20 | 20 | 70 |
| 9 | «Ел хатын-кызы.Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» Республика конкурсында катнашу | РБК, мәдәният бүлеге, ЯССБ, МБ | 2021-2024 еллар. | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 10 | Районныкын үткәрү һәм «Иделкәем» театр коллективларының республика конкурсында катнашу | мәдәният бүлеге, ЯССБ, МБ | 2021-2024 еллар. | 20 | 20 | 20 | 20 | 80 |
| 11 | «ВАТАН» яшьләр халык иҗаты фестиваль-конкурсы | «РМЙ» МБУ | 2021-2024 | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәдәният бүлеге, | еллар. | | | | | |
| 12 | «Чатыр тауда җыен» - төрки халыкларның халык иҗаты халыкара фестивале | «РМЙ» МБУ мәдәният бүлеге, | 2021-2024 еллар. | 10 | 10 | 10 | 10 | 4[illegible] |
| | **Барлыгы:** | | | **135,0** | **120,0** | **140,0** | **125,0** | **520,0** |

**9 . Кадрлар әзерләү һәм мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә социаль ярдәм күрсәтү**

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты (ел) | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | Барлыгы |
| 1 | Барлык дәрәҗәдәге белгечләргә ихтыяҗ мониторингы, мәдәният һәм сәнгать уку йортларына, шул исәптән максатчан юнәлешләр буенча да, белгечләр өчен гаризалар җибәрү һәм кабул итү планын формалаштыру. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, «ҮКС» МБУ, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2 | Югары һәм урта махсус уку йортларында белгечләрне максатчан әзерләүгә социаль сорау әзерләү. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, «ҮКС» МБУ, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3 | Югары һәм урта махсус мәдәният һәм сәнгать уку йортларында чыгарылыш укучылары ярминкәләрендә катнашу. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, «ҮКС» МБУ, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4 | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирү институты планы нигезендә мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең квалификациясен һәм һөнәри әзерлекләрен күтәрү. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, «ҮКС» МБУ, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 5 | 10 | 10 | 10 | 35 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Чыгарылыш сыйныф укучылары арасында һөнәри юнәлеш бирү эшенә, тәҗрибә уртаклашу юлы белән квалификацияне күтәрүгә багышланган чаралар (практикумнар, семинарлар, күрсәтмә чаралар, методик тикшерүләр һ.б.). | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, «ҮКС» МБУ, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | |
| 6 | Мәдәният хезмәткәрләрен бүләкләү законнары нигезендә мактаулы исемнәр бирүгә, бүләкләү грамоталары һәм башка мактау бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү. | Мәдәният бүлеге, «РМЙ» МБУ, «ҮКС» МБУ, «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ | 2021-2024 еллар. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | **Барлыгы:** | | | **5,0** | **10,0** | **10,0** | **10,0** | **35,0** |

Шартлы билгеләр:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (ТР ММ), Муниципаль бюджет учреждениеләре: «Район мәдәният йорты» («РМЙ»), «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» («ҮКС»), Үзәк балалар китапханәсе (ҮБК), Татарстан Республикасы Республика балалар китапханәсе (РТ РБК), «С.М.Лисенков исемендәге тарихи - туган якны өйрәнү музее» МБМУ, авыл мәдәният йортлары (АМЙ), авыл клублары (АК), «Әлки балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасы ( «БММ» МББ ӨББО), Мәгариф бүлеге (МБ), Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге(ЯССБ), Инфраструктур үсеш бүлеге (ИҮБ), авыл җирлекләре Башкарма комитетлары (АҖБК), район Башкарма комитеты (РБК).